Республика Татарстан
Совет Рангазарского сельского
поселения Сармановского
муниципального района

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Рангазар авыл җирлеге советы

**РЕШЕНИЕ**
**19.06.2024 года**

**КАРАР**
**№ 6**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Рангазар авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе дәүләт хезмәте системасы турында» Федераль законның 12 статьясына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 12 декабрендәге 594-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 79 статьясы һәм «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 28_1 статьясы, Сарман муниципаль районының «Рангазар авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Рангазар авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Сарман муниципаль районының Рангазар авыл җирлегенең 2022 елның 14 февралендәге 2 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Рангазар авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында Положениегә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1) 6.1 пунктның 8 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8) муниципаль хезмәткә кергәндә һәм (яисә) аны үткән чорда ялган документлар һәм (яисә) аны бозган өчен муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә тоткарлык ясый торган чикләүләрнең, тыюларның һәм таләпләрнең үтәлүен раслый торган, яисә документларның һәм (яисә) белешмәләрнең, муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә тоткарлык ясый торган чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәмәве турында таныклый торган белешмәләрне тапшырганда;»

2) 9.3 пунктның 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) «Россия Федерациясе дәүләт хезмәте системасы турында» Федераль законның 12 статьясына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 N 594-ФЗ Федераль законның 15_2 статьясында каралган анкета;»;

3) 9.4 пунктка «белешмәләр» сүзеннән соң «(анкетадагы белешмәләрдән тыш)» сүзләрен өстәргә.

4) 18.1 пунктындагы 11 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11) муниципаль хезмәткә кергәндә һәм муниципаль хезмәткәрләргә узган вакытта граждан тарафыннан тапшырыла торган белешмәләрне тикшерүне оештыру һәм үткәрү;».

5) 18.2 пунктындагы 10 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «максатчан уку турында шартнамә төзүгә конкурста катнашу хокукына Россия Федерациясе дәүләт телен белгән, тиешле дәрәҗәдәге һөнәри белем алучы һәм уку яисә башка килешү буенча мәҗбүри булмаган, уку тәмамланганнан соң хезмәт мөнәсәбәтләренең барлыкка килүенә китерә торган гражданнар ия.»;

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Рангазар авыл җирлеге
Советы рәисе Р.Н.Кыямов